| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.07.2024 п.г.т.Алексеевское № 262

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт турында**

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Алексеевск муниципаль районы Уставына ярашлы, Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Алексеевск муниципаль районы җирлекләре башкарма комитетлары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләрне гамәлгә ашыру максатларында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга. Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарын вәкаләтне гамәлгә ашыру өчен җаваплы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен расларга (Кушымта).

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://alekseevskiy.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
05.07.2024 ел, № _262_
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе**

Әлеге Тәртип «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Алексеевск муниципаль районы Уставы нигезендә ,Алексеевск муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен тормышка ашыру максатында эшләнгән.

Бүлек 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Алексеевск муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булып Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты тора

(алга таба-махсус хезмәт). Махсус хезмәт җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеген түләүсез нигездә күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

Үз эшчәнлегендә махсуслаштырылган хезмәт Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары, Алексеевск муниципаль районының муниципаль хокукый актлары, зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту, Татарстан Республикасында җирләү эшен оештыру буенча Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 01.04.2024 № 64/0 боерыгы белән расланган Методик тәкъдимнәр белән һәм әлеге Тәртип белән җитәкчелек итә.

1.2. Махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан күрсәтелә торган җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе Алексеевск муниципаль районының муниципаль акты белән раслана.

1.3. Махсус хезмәт физик яки юридик затлар белән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге кысаларында эшләрне башкаруга контрактлар (килешүләр) төзи.

Бүлек 2. Махсус хезмәтнең төп функцияләре һәм бурычлары

2.1. Җирләү эше өлкәсендәге вәкаләтләрнең бер өлешен район дәрәҗәсенә тапшыру турында килешүләр төзелгән торак пунктларның җәмәгать зиратларында махсуслаштырылган хезмәт җирләү буенча түбәндәге хезмәтләр

исемлеген түләүсез нигездә күрсәтә:

1) җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;

2) табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү;

3) үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка китерү;

4) җирләү.

2.2. Ире(хатыны), якын туганнары, башка туганнары яки үлгән кешенең законлы вәкиле булмаганда яки аларның җирләү мөмкинлеге булмаганда, шулай ук үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алучы башка кешеләр булмаганда, өйдә, урамда яки башка урында үлгән кешене ,эчке эшләр органнары аның шәхесен билгеләгәннән соң, үлем сәбәбен билгеләгәннән соң өч тәүлек дәвамында, әгәр башка Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса җирләү.

2.3. Шәхесләре Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вакытта эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнмәгән үлгәннәрне җирләү, әлеге органнарның ризалыгы белән, мондый очраклар өчен билгеләнгән җәмәгать зиратларында җирләү юлы белән махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан башкарыла.

2.4. Бу Тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән үлгәннәрне җирләгәндә махсус хезмәт тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр үз эченә ала:

1) җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;

2) мәетне киендерү;

3) табут бирү;

4) үлгән кешене зиратка алып бару;

5) җирләү.

2.5. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген башкару махсус хезмәт тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда башкарыла.

## Бүлек 3. Махсус хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга таләпләр

3.1. Махсуслаштырылган хезмәт җирләү һәм җирләү эше өлкәсендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәргә тиеш, шул исәптән:

-түләүсез нигездә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген бирү буенча дәүләт гарантияләре;

- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә кергән хезмәтләрнең сыйфатына таләпләр.

3.2. Махсус хезмәтнең кирәкле акча булмау сәбәпле яки башка нигезләр буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегеннән баш тартуы рөхсәт ителми.

3.3. Махсус хезмәт хокуклы түгел:

1) үлгән кешенең ихтыярын үтәүче, шулай ук үлгән кешенең ире(хатыны), якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкилләре, үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар исеменнән һәм кушуы буенча эш итүче затларга җирләүне гамәлгә ашыруга (шул исәптән үлгән кешене җирләү юлы белән) комачауларга;

2) махсус хезмәттән ритуаль хезмәтләр, шул исәптән түләүле нигездә җирләү буенча хезмәтләр исемлегенә кергән хезмәтләр сатып алырга мәҗбүр

итәргә (мәжбүрләргә).

## Бүлек 4. Махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибенә төп таләпләр

4.1. Махсус хезмәт жирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерә, җирләү датасын һәм вакытын үлгән кешенең гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә, шулай ук диненә туры китереп билгели.

Документларны рәсмиләштерү нәтиҗәләре буенча махсуслаштырылган хезмәт әлеге Тәртипнең 2 бүлегенә ярашлы рәвештә жирләү буенча хезмәт күрсәтә.

4.2. Махсус хезмәт консультатив ярдәм күрсәтә:

жирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген башкару тәртибе буенча;

зиратларның эш кагыйдәләре буенча;

жирләүгә социаль пособие бирү тәртибе һәм күләме буенча һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә жирләү һәм жирләү эше өлкәсендә гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү тәртибе буенча.

4.3. Махсус хезмәт бинасында түбәндәге мәжбүри мәгълүмат булырга тиеш:

1) Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы «Кулланучылар хокукларын яклау турында»гы Законы;

2) «Җирләү һәм жирләү эше турында»1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон;

3) Россия Федерациясе Президентының 1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы Указы

«Гражданнарның үлгәннәрне жирләү буенча хезмәтләр күрсәтүгә хокуклары гарантияләре турында»;

4) жирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге.

## Бүлек 5. Махсус хезмәт җаваплылыгы

Җирләү һәм жирләү эше өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен махсуслаштырылган хезмәт гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә җаваплы.